# Балтач гимназиясе укучылары бәйгедән кабат җиңү белән кайтты

Күптән түгел Казан шәһәрендә булып узган бәйгедә Балтач гимназиясенең 4нче И сыйныфы укучылары икенче дәрәҗә лауреат исеменә лаек булды. Бәйгедә Рәсәйнең төрле шәһәрләреннән бик зур әзерлек белән килгән, махсус белемле режиссерлар әзерләгән театр коллективлары булуга карамастан, укучылар инглиз телендә спектакль белән уңышлы чыгыш ясады. Җитәкчеләре инглиз теле укытучысы Миләүшә Гариповна һәм сыйныф җитәкчесе Алсу Камиловна коллективны зур сәхнәгә чыгарлык дәрәҗәдә әзерләделәр. Рәхмәт аларга!

